| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Кичкетанского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кичкетан авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.10.2018 Кичкетаң авылы № 3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге Барҗы-Умга авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетан авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетан авыл җирлеге башлыгы, к а р а р  б и р д е:

1.2018 елның 26 октябренә Барҗы-Умга авылы клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 10 сәгатькә билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга: «I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан, Кичкетаң авыл җирлеге Барҗы Умга авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2019 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1. Гомуми файдаланудагы юлларны ремонтлау
2. Күмү урыннарын карап тоту.
3.Барҗы-Умга авылы урамнарын кардан чистарту.
4.Санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3.Кичкетаң авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрүне йөкләргә.

4.Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында.бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

З.Р.НУРИЕВ